**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
АКТАНЫШСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АКТАНЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

пр. Ленина, дом 17, с.Актаныш, 423740

Ленин пр.,17йорт,Актаныш ав., 423740

Тел.(85552)3-44-22,факс(85552)3-44-14,E-mail: aktanysh@tatar.ru, www.aktanysh.tatarstan.ru

ПОСТАНОВЛЕНИЕ — КАРАР

______________ ______________

Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 1 июнендәге ПР-106 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында

«Дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә муниципаль милектәге җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 29 декабрендәге 1221 номерлы карары нигезендә, «Муниципаль милектәге җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә, шулай ук дәүләт милке чикләнмәгән җирләрдә яисә җир кишәрлекләрендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2016 елның 13 августындагы 553 номерлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы Советының 2021 елның 08 февралендәге «Актаныш муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибе турында» Актаныш муниципаль районы Советының 2020 елның 28 апрелендәге 46-05 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 07-07 номерлы карары белән Актаныш муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында»гы 2020 елның 01 июнендәге ПР-106 номерлы карары белән расланган, Актаныш муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибенә, 7 бүлекнең 7.4 пунктчасын «4» абзац белән тулыландырып, түбәндәге үзгәреш кертергә:

- «4) хуҗалык итүче субъектта салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәлмәгән бурычлары булган очракта»

2. Актаныш муниципаль районы Башкарма комитетының «Актаныш муниципаль районы территориясендә стационар булмаган сәүдә объектларын урнаштыру тәртибен раслау турында» 2020 елның 1 июнендәге ПР-106 номерлы карарының 2 нче кушымтасына, 6 бүлекнең 6.1. пунктчасын «е» абзацы белән тулыландырып, түбәндәге эчтәлекле үзгәреш кертергә:

- «е) хуҗалык итүче субъектта салымнар, җыемнар, иминият взнослары, пенялар, штрафлар, процентлар түләү буенча Россия Федерациясе законнары нигезендә үтәлмәгән бурычлары булган очракта».

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көннән законлы көченә керә һәм районның рәсми сайтында, http://pravo.tatarstan.ru/ адресы буенча, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук Татарстан Республикасы

муниципаль берәмлекләре Порталында Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://aktanysh.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырылырга тиеш.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче И.И.Габдулхаев